Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге
Екатериновка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2 ноябрь, 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлегенең Екатериновка торак пунктында 2025 елның 2 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 60 (алтмыш).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 36 (утыз алты).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 30 (утыз).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 6 (алты).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 маддәсенең 6 өлеше нигезендә, «Сез Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлегенең Екатериновка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, махсус хәрби операция катнашучыларын һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән ризамы:

- Екатериновка авылы чикләрендә гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Переулочная урамы)» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены карары» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Екатериновка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Екатериновка авыл җирлеге башлыгы П.И. Егоров